ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 14

Иске Каразирек ав. 26 декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2024 елның 10 декабрендәге 30 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлегендә бюджет процессы турында"гы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2024 елның 10 декабрендәге 30 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлегендә бюджет процессы турында»гы нигезләмәгә (алга таба-нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 33 маддәсендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары (җирле бюджетлар), бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчаларын алучыларның һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда һәм тәртиптә кире кайтарылырга яисә күчерелергә тиешле акчаларның Россия Федерациясе законнары нигезендә федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъектының финанс органыннан, бюджеттан тыш фонд белән идарә органыннан үзләренә тиешенчә Федераль казначылыкта, Россия Федерациясе субъектының финанс органыннан (муниципаль берәмлектә) ачыла торган исәп-хисапларны исәпкә алу, әлеге чаралар Федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә караган һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынган очрактан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев